**Консультация для родителей ИМС 3**

# ПОДГОТОВКА ДЕТЕЙ К ШКОЛЕ
# ДЕТИ НА ШКОЛЬНОМ СТАРТЕ – ЗАБОТЫ ПЕДАГОГОВ И СЕМЬИ

**Амирова Гульсияр Раисовна,**
**старший воспитатель ДОУ №95,**
**специалист консультационного центра**

Уважаемые родители! Скоро перед детьми распахнёт двери школа и начнется новый период в их жизни. Они станут первоклассниками, а вы дорогие мамы и папы станете родителями школьников.
Подготавливая ребенка к школе необходимо научить его слушать, видеть. Наблюдать, запоминать, перерабатывать полученную информацию. Что необходимо знать и уметь ребенку, поступающему в школу?

## ЧТО НЕОБХОДИМО ЗНАТЬ И УМЕТЬ РЕБЁНКУ, ПОСТУПАЮЩЕМУ В ШКОЛУ

1. Своё имя, отчество и фамилию.
2. Свой возраст (желательно дату рождения).
3. Свой домашний адрес.
4. Свой город, его главные достопримечательности.
5. Страну, в которой живёт.
6. Фамилию, имя, отчество родителей, их профессию.
7. Времена года (последовательность, месяцы, основные приметы каждого времени года, загадки и стихи о временах года).
8. Домашних животных и их детёнышей.
9. Диких животных наших лесов, жарких и холодных стран, их повадки, детёнышей.
10. Транспорт наземный, водный, воздушный.
11. Различать одежду, обувь и головные уборы; зимующих и перелётных птиц; овощи, фрукты и ягоды.
12. Знать и уметь рассказывать русские (татарские) народные сказки.
13. Различать и правильно называть плоскостные геометрические фигуры: круг, квадрат, прямоугольник, треугольник, овал.
14. Свободно ориентироваться в пространстве и на листе бумаги (правая - левая сторона, верх - низ и т. д.)
15. Уметь полно и последовательно пересказать прослушанный или прочитанный рассказ, составить, придумать рассказ по картинке.
16. Запомнить и назвать 6-10 картинок, слов.

17. Различать гласные и согласные звуки.
18. Разделять слова на слоги по количеству гласных звуков.
19. Хорошо владеть ножницами (резать полоски, квадраты, круги, прямоугольники, треугольники, овалы, вырезать по контуру предмет).
20. Владеть карандашом: без линейки проводить вертикальные и горизонтальные линии, рисовать геометрические фигуры, животных, людей, различные предметы с опорой на геометрические формы, аккуратно закрашивать, штриховать карандашом, не выходя за контуры предметов.
21. Свободно считать до 10 и обратно, выполнять счётные операции в пределах 10.
22. Уметь внимательно, не отвлекаясь, слушать (30 – 35 минут)
23. Сохранять стройную, хорошую осанку, особенно в положении сидя.

Подготовка ребенка к школе – это целый комплекс знаний, умений и навыков, которыми должен владеть дошкольник. В литературе существует множество классификаций готовности ребенка к школе, но все они сводятся к одному: готовность к школе подразделяется на *физиологический, психологический* и *познавательный аспект*, каждый из которых включает в себя целый ряд составляющих. Все виды готовности должны гармонично сочетаться в ребенке. Если что-то не развито или развито не в полной мере, то это может послужить проблемам в обучении в школе, общении со сверстниками, усвоении новых знаний.

**ЧТО НУЖНО ЗНАТЬ РОДИТЕЛЯМ, ЗАНИМАЯСЬ С РЕБЕНКОМ ДОМА?**

Домашние занятия с ребенком очень полезны и необходимы будущему первокласснику.

Но такие занятия не должны быть для ребенка принудительными, его необходимо в первую очередь заинтересовать.

Не надо отрывать ребенка от игр и сажать его за стол, а постарайтесь увлечь его, чтобы он сам принял ваше предложение позаниматься.

Кроме этого, занимаясь с ребенком дома, родители должны знать, что в пять-шесть лет дети не отличаются усидчивостью и не могут долгое время выполнять одно и то же задание.

Занятие дома не должно продолжаться более пятнадцати минут. После этого следует сделать перерыв, чтобы ребенок отвлекся.

Очень важна смена деятельности. Например, сначала вы в течение десяти-пятнадцати минут выполняли логические упражнения, потом после перерыва можно заняться рисованием, далее поиграть в подвижные игры, после чего полепить из пластилина забавные фигуры и т. п.

Все задания должны преподноситься малышу в игровой форме, а домашние занятия не должны превращаться в учебный процесс.

Большую помощь родителям могут оказать различные развивающие игры, но при этом очень важно, чтобы они соответствовали возрасту ребенка.

Разучивайте с ребенком скороговорки и стихотворения, пословицы.

**ТРЕНИРУЕМ РУКУ РЕБЕНКА**

Дома очень важно развивать мелкую моторику ребенка, то есть его руки и пальчики. Это необходимо для того, чтобы у ребенка в первом классе не было проблем с письмом. Многие родители совершают большую ошибку, запрещая ребенку брать в руки ножницы. Да, ножницами можно пораниться, но если с ребенком проговорить, как правильно обращаться с ножницами, что можно делать, а что – нельзя, то ножницы не будут представлять опасности. Некоторые родители не уделяют должного внимания развитию мелкой моторики ребенка. Как правило, по причине незнания, насколько важно это для успешного обучения ребенка в первом классе. Известно, что наш ум лежит на кончиках наших пальцев, то есть чем лучше у ребенка развита мелкая моторика, тем выше его общий уровень развития. Если у ребенка плохо развиты пальчики, если ему трудно вырезать и держать в руках ножницы, то, как правило, у него плохо развита речь и он отстает по своему развитию от сверстников. Именно поэтому логопеды рекомендуют родителям, чьи дети нуждаются в логопедических занятиях, одновременно заниматься лепкой, рисованием и другими занятиями на развитие мелкой моторики.

**ПАМЯТКА**
**РОДИТЕЛЯМ ВЫПУСКНИКА ИЗ ДЕТСКОГО САДА**.

1. Своевременно **определитесь с выбором школы**: желательно ещё осеньюпознакомить ребенка с будущим учителем.
2. **Следите за здоровьем ребенка**: своевременно лечите хронические заболевания, контролируйте осанку, зрение, слух ребенка, позаботьтесь о прививках, вылечите зубы при необходимости.
3. Организуйте полноценный летний отдых: **дети выпускаются из детского сада 31 мая**, заранее продумайте где, под чьим присмотром ребенок проведет лето.

**Успешного вхождения в школьный коллектив!**

**Пусть учеба для ваших детей будет в радость!**

**Ата-аналар өчен консультация <u>ИМС 4</u>**

**БАЛАНЫҢ МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕГЕ.**

**(Подготовка детей к школе)**

**Амирова Гульсияр Раисовна,**
**старший воспитатель ДОУ №95,**
**специалист консультационного центра**

Баланың мәктәпкә әзерлеге берничә күрсәткечтән тора:

1. <u>Физик яктан әзерлек.</u>

Бала мәктәптә яхшы укысын өчен ул тиешле дәрәҗәдә физик яктан нык һәм әзерлекле булырга тиеш. Бары аң ягыннан һәм физик яктан дөрес үсеш алган бала гына акыл эшчәнлеге белән уңышлы шөгыльләнә ала. Физик әзерлек өчен җаваплылык тулысынча эти - әнигә һәм балалар табибына йөкләтелә. Бала тудыру йортыннан алып мәктәпкә кергәнче бала зур физик үсеш юлы үтә. Һәр бала да сау сәламәт булып тумаска мөмкин. Күп кенә ата – ана беренче урынга баланың сәламәтлеген ныгытуга, булган авыруларны мәктәпкә кергәнче я бөтенләй дәвалап бетерергә, я өлешчә генә булса да уңай якка үзгәртергә тырыша. Бу максаттан чыгып түбәндәге чараларны үткәрү зарур:

- Балалар табибы белән һәрдаим элемтәдә булу.
- Авырган очракта авыруны мөмкин кадәр ахырына кадәр дәвалау. Ягъни хроник авыруга әйләндермәү.
- Шифаханәләрдә дәвалану.
- Дөрес туклануга әһәмият бирү.
- Спорт белән шөгыльләнү.
- Гаиләдә уңай психологик халәт, дуслык тудыру.
- Балага бары уңай яктан үрнәк күрсәтү.

Шулай ук көндәлек режимны тоту, аны бозмау әһәмиятле. Балалар бакчасына йөргән балалар киенә, савыт-сабаларны дөрес куллана, билгеле вакытта йокларга ятарга, вакытында иртәнге аш, көндезге аш, кичке аш ашарга, уйнарга, саф һавада йөрергә өйрәнгән. Шул ук режимны бала мәктәптә дә төгәл үтәргә тиеш. Дөрес оештырылган көн – сәламәтлек нигезе. 6-7 яшьлек бала тәүлегенә 11-12 сәгать йокларга тиеш. Төнге йокы балага алган белемнәрен системалаштырырга, стресслардан арынырга ярдәм итә. Көндезге йокы да бала өчен мәҗбүри.

2. <u>Шәхси әзерлек.</u>

Мәктәпкә беренче тапкыр укучы сыйфатында бару – балага зур җаваплылык өсти. Бала бу көнне ашкынып көтә, нәни йөрәге күпме дулкынландыргыч хисләр кичерә. Бу хисләрне дә эти - әни тәрбияли. Балага мәктәпне, мөгаллимнәрне өйдә ничек сурәтлиләр, бала шулай кабул итә. Хәзерге алдынгы карашлы эти - әни баланы мәктәпкә дөрес әзерләргә тырыша. Бу беренче көннән үк күзгә ташлана. Кызганычка каршы, кайбер тискәре фикерләр белән ышандыручылар да күзәтелә. Бу очракта түбәндәге киңәшләр артык булмас.

- Баланы мәктәпнең тышкы ягы белән түгел, ә белем алу учагы булуы белән кызыксындыру зарури.
- Баланы беркайчан да гел «5» кә генә укырга өндәргә ярамый. Бигрәк тә беренче адымны ясаганда. Барлык фәннәрне «5» кә үзләштерү өчен нинди

кыенлыкларны җиңәргә кирәк икәнлеген, кечкенә уңыштан зур уңыш килүен аңлату отышлырак була.

- Баланы үзе кылган гамәленә җавап тотарга өйрәтү. Бу иң мөһим сыйфатларның берсе.
- Башлаган эшне ахырына җиткерү.
- Үзеңнең һәм иптәшеңнең фикерен хөрмәт итү.
- Мәктәп «усал укытучы», начар билгеләр белән куркытмау.

3. Акыл әзерлеге.

Баланың иң беренче мөгаллиме - ата-ана.

Гаиләдә әти - әни эчкерсез, еш аралашырга сөйләшергә ярата икән, бала да шул сыйфатларны үзенә ала.Сөйләшергә яраткан бала күзәтүчән, кызыксынучан, кешеләр белән тиз аралашучан булып үсә.Шуңа күрә баланы мәктәпкә әзерләгәндә аның әйләнә-тирә дөньяга күзаллавын киңәйтергә кирәк:
Ни өчен ел фасыллары үзгәрә?
Агачлар ничек үсә?
Кешегә ни өчен баш, борын, колаклар кирәк?
Ни өчен төрле халыклар була?
Син нинди һөнәрләр беләсең?
Әгәр урамда берәр кеше егылса, син нишләр идең?
«Туган тел» шигырен кем язган? һ.б.

Шундый сорауларга җаваплар эзләү баланың фикерләү сәләтен үстерә, логик фикер эшчәнлеген арттыра. Сорауларга җавапларны төрле китаплардан, белешмәләрдән, интернет челтәреннән табарга мөмкин.

Балалар һәрвакыт күп сораулар бирергә яраталар. Әти - әни иренмичә җавап бирсә, бала акыл ягыннан югары үсешкә ия була.

Бала тууга аның белән авазларны бозмыйча, ягъни олылар белән сөйләшкәнчә сүзләрне дөрес әйтеп сөйләшергә кирәк. Баланың авазларны бозып сөйләшүе 4-5 яшькә төгәлләнергә тиеш. Әгәрдә дөрес, ачык итеп сөйләшергә өйрәнмәсә, баланы киләчәктә укуында зур хаталар, кимчелекләр көтә. Үз вакытында яхшы специалистларга күренү, һәм ярдәм кулы сузу балага яхшы киләчәк фаразлый.

Баланы мәктәпкә әзерләгәндә: «Әйдә укыйк әле», - дип түгел, ә бәлки «Әйдә уйныйк әле», - диярргә кирәктер. Кечкенә нарасый уен аша, кубиклардан иҗек, сүз төзергә өйрәнә. Бала ата-ананың укуын ишетеп үсергә тиеш. Бер үк әсәрне бала әллә ничә тапкыр тыңларга теләве бар. Бала шулай акыл эшчәнлеген баета. Хәтер, уйлау, фикерләү сәләтен үстерә. Матур әдәбият әсәрләрен сөйләргә өйрәнә. Сөйләмендә тулы һәм ким җөмләләр куллана башлый.

Кечкенә генә уңышын күрә белү, мактау да балада ышаныч тудыра.

Һич кенә дә уңышсызлыкка очраган балага тупас сүз әйтергә, аның шәхесен кимсетергә ярамый.

Иң кыйммәтле киңәш: балаңны ничек бар шулай кабул ит һәм ярат. Ул синең йөрәк җимешең. Без аны уңышлары өчен генә түгел, ә бу дөньяда яшәгәне, сау - сәламәт булганы өчен дә яратырга тиешбез. Бала үзе иң зур бүләк.
Уңышлар сезгә!